**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**К А Р А Р**

«21» 10 2024 ел Яр Чаллы ш. № 107

2024 - 2025 елгы көзге-кышкы янгын куркынычы чорында муниципаль районның авыл хуҗалыгы объектларында һәм торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын көчәйтү турында

Янгыннар аркасында барлыкка килгән катлаулы хәлләргә әзерлекне арттыру һәм авыл җирлекләренең торак пунктларын, муниципаль район объектларын һәм предприятиеләрен көзге-кышкы янгын куркынычы чорына вакытында әзерләү максатыннан,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. ТР буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Тукай муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр бүлеге башлыгы И.И. Мифтаховның 2023 - 2024 елгы көзге-кышкы янгын куркынычы чорында янгыннар аркасында булган хәлләр турында мәгълүматын исәпкә алырга.

2. Муниципаль районның авыл җирлекләре башлыкларына һәм хуҗалыклар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- кызыксынган затларның беркетелгән территорияләрдә (торак пунктларда һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе объектларында) янгынга каршы тышкы суүткәргечне көзге тикшерүдә катнашуын оештырырга;

- янгынга каршы су белән тәэмин итүне төзек хәлдә тоту, кышкы чорда аның җылытылуын һәм алардан янгын сүндерү техникасы белән су алуны җайлау буенча чаралар күрергә;

- табигый сулыкларны туңмый торган бәкеләр белән тәэмин итәргә;

- янгынга каршы су чыганакларына керү юлларын ачык тотарга, шулай ук аларны кышкы чорда кардан һәм боздан чистартуны оештырырга.

3. Җылылык мичләрен файдаланганда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу сәбәпле янгыннарны кисәтү максатында, муниципаль район авыл җирлекләре башлыкларына, «Бөтенроссия ирекле янгын сүндерү җәмгыяте» Татарстан Республикасы бүлегенең Чаллы бүлекчәсе вәкилләре һәм Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе Тукай муниципаль районы буенча күзәтчелек һәм профилактика эше бүлегенең янгын күзәтчелеге буенча дәүләт инспекторлары белән берлектә, тәкъдим итәргә:

– торак пунктларның шәхси торак секторында мич белән җылытуны тикшерүне оештыруырга.

4. Авыл җирлекләре башлыкларына, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә, муниципаль районның торак оешмалары һәм хуҗалык җитәкчеләренә, муниципаль районның энергия күзәтчелеге хезмәтләре һәм муниципаль районның кызыксынган хезмәтләре вәкилләре белән берлектә, терлекчелек комплексының, кешеләр күп була торган объектларның янгынга каршы торышына комиссия тикшерүен оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Муниципаль районның авыл җирлекләре башлыкларына һәм хуҗалыклары җитәкчеләренә кешеләрне, мөлкәтне эвакуацияләү, янгыннарны сүндерү буенча беренчел чаралар күрү, Татарстан Республикасы буенча Федераль янгынга каршы хезмәтнең 15 нче янгын-коткару отрядының шәһәр бүлекчәләре һәм Татарстан Республикасы Янгынга каршы хезмәтнең аерым постлары килеп җиткәнче, машина йөртүчеләрнең һәм ирекле янгын формированиеләре муниципаль һәм объект бүлекчәләре әгъзаларының җылытыла торган гаражларда һәм җайлаштырылган биналарда, төзек янгын сүндерү һәм янгын сүндерүгә җайланган техника белән тәүлек әйләнәсе кизү торуын оештырырга тәкъдим итәргә. Шулай ук Яр Чаллы шәһәренең Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә (01, 112) җирле үзидарә органнарының һәм хуҗалыкларның ирекле (муниципаль) янгын сүндерү формированиеләренең хәрби әзерлеге (атап әйткәндә, янгын һәм җайлаштырылган техниканың төзеклеге, машина йөртүче һәм ягулык булуы) турында мәгълүматны көн саен тапшыруны шәхси контрольгә алуны тәкъдим итәргә. Янгын формированиеләре техникасын билгеләнеше буенча кулланмауны катгый тыярга.

6. Авыл җирлекләре башлыкларына, муниципаль районның торак оешмалары җитәкчеләренә, Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлекләре, Россия ГТХМ Тукай муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге һәм Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең «Биклән», «Комсомолец», «Теләнче-Тамак» һәм «Күзкәй» аерым постлары хезмәткәрләрен, Ирекле янгын формированиеләренең муниципаль бүлекчәләре һәм Яшь янгын сүндерүчеләр дружиналарын җәлеп итеп, халык һәм хуҗалык хезмәткәрләре арасында, янгыннарны һәм аларның нәтиҗәләрен кисәтү, шулай ук янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итү максатыннан, ялгыз, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, спиртлы эчемлекләрне артык куллануга һәвәс затларга һәм имин булмаган гаиләләргә аерым игътибар биреп, эшне активлаштырырга.

7. Муниципаль районның авыл җирлекләре башлыкларына, хуҗалыклары җитәкчеләренә, мәгариф идарәсе башлыгына балалар, укыту, мәдәни-тамаша учреждениеләре, терлекчелек биналары объектларын тәүлек әйләнәсе саклауны, шулай ук әлеге объектларда җаваплы затларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

8. Авыл җирлекләре башлыкларына, муниципаль районның торак оешмалары һәм хуҗалык җитәкчеләренә янгынга каршы пропаганда үткәрүне, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, Гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстәмә профессиональ программаларны раслау турында» 2021 елның 5 сентябрендәге 596 номерлы, «Оешмаларда эш яки хезмәт эшчәнлеген башкаручы

затларның янгынга каршы инструктаж программалары буенча укыту тәртибен, төрләрен, срокларын, күрсәтелгән программаларны һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстәмә һөнәри программалар буенча белем алучы затларның категорияләрен билгеләү турында» 2021 елның 18 ноябрендәге 806 номерлы боерыклары нигезендә вазифаи затларны һәм яшәү урыны буенча халык арасында янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча аңлату эшләре алып баручы затларны янгын-техник минимум программасы буенча укытырга тәкъдим итәргә.

9. Мәгариф идарәсе башлыгына уку барышында «Тормыш иминлеге нигезләре» дәресләрен үткәрергә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен өйрәтергә тәкъдим итәргә.

10. Әлеге карарны кирәкле урынга, затларга җиткерергә.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

12. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинга һәм район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Р.В. Хәбетдиновка йөкләргә.

Тукай муниципаль районы Башлыгы
вазифаларын башкаручы — Р.И. Закиров